Килешенде:
Педагогик киңәшмә утырышында
тикшерелде һәм кабул ителде

2018 нче елда педагогик
киңәшмәдә расланды
Беркетмә № 1 (29.08. 2018)
Педагогик киңәшмә рәисе:
_________ Р.Я. Бадретдинова

# Азнакай муниципаль районы МББМБУ Уразай авылы «Айгуль» балалар бакчасы» катнаш төркем балалары өчен 2018-2019 нче уку елына эш планы.

**2018 ел**

# Эчтәлек


| | |
|---|---|
| **1. Бүлек.** | |
| 1.1 Белем һәм тәрбия эшенең анализы | 4-9 |
| 2. Методик тема, 2018-2019 уку елына төп бурычлар | 10 |
| **2. Бүлек.** | |
| 3. Белем турында законның үтәлеше | 11 |
| **3. Бүлек : Кадрлар белән эшне оештыру.** | |
| 3. Кадрлар белән эш, хезмәткәрләрнең социаль активлыгын һәм һөнәри квалификациясен күтәрү | 12-14 |
| 4. Алдынгы тәҗрибәне тарату | 14 |
| **4. Бүлек: Фәнни методик мәгълүмәт** | |
| 5. Методик бүлмәне баету өстендә эш | 15 |
| 6. Гомуми җыелышлар | 16 |
| 7. Педагогик киңәшмәләр | 17-20 |
| 8. Ачык чаралар, бәйгеләр | 20-21 |
| **5. Бүлек: Укыту-тәрбия эшен яхшыртырга юнәлтелгән эшчәнлек** | |
| 9. Сәламәтләндерү, профилактик эш,күргәзмәләр | 21-23 |
| 10. Ел буена үткәреләсе атналыклар | 23-25 |
| 11. Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре | 25-26 |
| 12. Күренекле шәхесләр белән очрашу | 26 |
| 13. Күргәзмәләр | 26-27 |
| 14. Консультацияләр | 27-28 |
| 15. Укыту –тәрбия процессында педагогик контроль | 29 |
| 16. Административ – хуҗалык эше | |
| | |
| **Кушымта :** | |
| | |
| 1. Белем бирү-тәрбия эшен планлаштыру | |
| 2. Ата-аналар белән эш планы | |
| 3. Ата – аналар комитеты эш планы | |
| 4. Балалар бакчасы һәм мәктәп белщн эш планы | |
| 5. Җәйге сәләмәтләндерү планы | |
| 6. Әхлак тәрбиясе буенча эш планы | |
| 7. Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча эш планы | |
| 8. Тормыш иминлеген саклау кагыйдәләренә өйрәтү буенча эш планы | |

**I НЧЕ БҮЛЕК**

1. **Балалар бакчасы турында кыскача мәгълүмат**
2. **Бакчаның исеме:** МБМББУ - ТатарстанРеспубликасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “ Айгуль” балалар бакчасы.

Балалар бакчасы 1992 елда ачылган.

3. **Адрес:** 423330, ТР, Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Н.Бәдертдинов урамы, 35 йорт.
4. **Электрон почтаның адресы: DUraz azn@mail.ru**
5. **Төркемнәр саны:** 1 (төрле яшьтәге балалар төркеме)
6. **Балалар саны**: 12 бала.
7. **Бакча мөдире:**
   **Бадретдинова Резеда Яшәр кызы**

Педагогик стажы: 25 ел

Бу вазыйфада: 23 ел

8. **Тәрбиячеләр:**

**Марданшина Гульнара Зөфәр кызы**

Педагогик стажы: 22 ел
Бу вазыйфада: 19 ел
1 квалификацион категория

**Садыкова ЗөлфияРафаэль кызы**

Педагогик стажы: 29 ел
Бу вазыйфада: 24 ел
1 квалификацион категория

**9. 2016-2017 уку елында балалар бакчасының белем бирү эшчәнлеге түбәндәге документларга нигезләнеп алып барылды:**

1. Закон «Об образовании» РФ .
2. «Конвенция о правах ребенка» .
3. Конституция РФ от 12.12.1993г (с изменениями и дополнениями).
4. Примерная основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад «Айгуль» с. Уразаево Азнакаевского муниципального района РТ.
5. «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы ДОУ» СанПиН 2.4.1.3049-13, от 24.01.2013г.
6. Лицензия на право ведения образовательной деятельности.

**2017-2018 нче уку елынадагы**
**эшчәнлеккә кыскача анализ.**

2017-2018 нче уку елында Уразай авылы “Айгуль” балалар бакчасына 12 бала йөрде. 10 малай, 2 кыз, катнаш тәркем. Мәктәпкә 2 бала китте.

Коллектив үз алдына түбәндәге бурычларны куеп эшләде:

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.
2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга кече яшьтән юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, тормыш иминлекләрен саклау
3. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.
4. Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек.
5. Балаларны ике Дәүләт телләренә, яңа УМК нигезендә сыйфатлы өйрәтүне түэмин итәргә.
6. Федераль Дәүләт белем стандартлары таләпләренә таянып, инновацион белем бирү программаларын һәм технологияләрне кулланып, педагогларның һөнәри белем дәрәҗәләрен күтәреп, балаларны мәктәпкә әзерләүнең сыйфатын үстерергә.
7. Әти-әниләрне балаларга ике дәүләт телен өйрәтү буенча яңа укыту-методик комплектлар белән таныштыруны дәвам итү, балаларга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттырырга.

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куеп эшләдек:

- хәрәкәт бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр баланың үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;

- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклап үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Район педиатры тарафынан балаларны тикшерү үткәрелде. Тәрбиячеләребез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды.


Бакчада физкультура дәресе зурлар төркемендә өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды.

Грипп, ОРЗ чорында группада сарымсак инголяциясе ясалды. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды.Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау ясап куйдык. Кыш буе балалар рәхәтләнеп шудылар, уйнадылар.

Менюда ризыклар төрләндерелде, аксымга бай продукцияләр, яшелчә, җиләк-җимешләр белән балалар тукландырылды.

Соңгы өч ел эчендә балаларның авырып калдырган көннәр саны:

2015-2016 ел 2016-2017 ел 2017-2018 ел



Бакчабызда шулай ук балаларга кече яшьтән үк табигатьне саклау, туган - төбәккә ихтирам хисе, сакчыл караш тәрбияләү бурычы да тора.

Балаларга табигатьнең гүзәллеген, аның байлыгы белән таныштыру,файдалы үлән, чәчәк, җәнлек,бөҗәкләрне таный белергә өйрәтү, сакчыл караш тәрбияләү максатыннан, безнең балалар бакчасында да экологик тәрбия бирү эшенә нык игътибар ителде, эшләрне планлы рәвештә алып барырга тырыштык. Белгәнебезчә балаларның сәламәтлеге, яшәеше турыдан-туры әйләнә-тирә мөхиткә бәйле. Шушыларны искә алып, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, махсус экологик тәрбия бирү буенча еллык эш планын төзелде.

Табигатьтә балаларны үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен, кагыйдәләрне төгәл үтәү йөзеннән күп кенә күрсәтмә җиһазлар, дидактик уеннар булдырылды.

Бүлмәләрдә бик күп төрле гөлләр үстердек. Гөлләрнең төрлелеге, матурлыгы сабыйларның күңелләренә ямь бирә Тәрбиячеләр белән берлектә гөлләрне карап, тәрбияләп, танып, исемнәрен әйтә өйрәнделәр.

Тәрбиячеләребез балаларга, тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә туры килә торган яңа программалар, яңа технологияләр кулланып эшен оештыралар. Төп программадан тыш үзебезнең эш тәҗрибәбездә рәсемнән Р.Г.Казакованың “Нетрадиционные техники рисования с детьми дошкольного возраста», Н.Сергееваның “Татар сынлы сәнгате”, сөйләм үстерүдән М.Ф.Кашапованың методик ярдәмлекләрен кулланабыз. Төзүдән Т.И.Тарабаринаның “Оригами и развитие ребенка”, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Авазларны уйнатып” түгәрәгендә Гаврина С.Е, Крутявина Н.Л, Топоркова И.Г., Щербинина С.В авторларның “Развиваем руки-чтоб учиться и писать, и красиво рисовать” ярдәмлекләреннән файдаланабыз Хәзер исә ФГОС таләпләренә туры килерлек методик ярдәмлекләр, дидактик уеннар алырга тырышабыз. Үзләренең уңганлыклары, эзләүчәнлекләре, балаларны яратулары нәтиҗәсендә тәрбиячеләребез эти-әниләр арасында да, коллективта да үзен уңай яктан гына күрсәтәләр, республика, региональ,зона һәм район күләмендә үткәрелгән конкурсларда, семинарларда, төрле мероприятияләрдә актив катнашып тордылар.

Тәрбияче Марданшина Гөлнара Зөфәр кызы Россия, республика һәм район күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә катнашып түбәндәге нәтиҗәләргә иреште:

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешендә дистанцион чаралар үзәге “БЭБИ-АРТ” үткәргән Россиякүләм “Куркынычсызлык дәресләре” дистанцион педагогик конкурсында 1 урын .

Район күләмендә уздырылган:

“Көзге фантазияләр” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 2 урын;,

“ Символ года 2018” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 1 урын

“Ель 2018 ” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 2 урын;

“ Символ года” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 1 урын;

“ Символ года” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 1 урын.

Тәрбияче Садыкова Зөлфиян Рафаэль кызы Россия, республика һәм район күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә катнашып түбәндәге нәтиҗәләргә иреште:

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешендә дистанцион чаралар үзәге “БЭБИ-АРТ” үткәргән Россиякүләм “Куркынычсызлык дәресләре” дистанцион педагогик конкурсында 1 урын .

Район күләмендә уздырылган:

“Көзге фантазияләр” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 1 урын;,

“ Символ года 2018” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 3 урын

“Ель 2018 ” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , сертификат;

“ Подводный мир” кул эшләре һәм рәсем сәнгате конкурсында , 1 урын;

Проектор һәм ноутбукның булуы балаларга татар һәм рус телләрендә мультфильмнәр карарга ярдәм итте. Интернеттан алган күрсәтмә материалларны проектор ярдәмендә эшчәнлекләрдә балаларга күрсәтергә бик уңайлы булды.

Хәзерге көндә ата-аналарның, педагогларның иң борчыган мәсьәләләрнең берсе – баланың акыл һәм физик яктан сәламәт булуы. Шуларны искә алып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик һәм акыл үсешләрен тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү йөзеннән, ФГОСталәпләренә туры килерлек яңа бурычлар куеп, үзгәрешләр кертеп эшебезне оештырырга тырышабыз.

Гомумән, ел дәвамында педагогларыбыз төрле дәрәҗәләрдә үткәрелгән семинарларда, методик киңәшмәләрдә эш тәҗрибәләре белән уртаклашып тордылар.Балалар бакчасында әти-әниләр белән эш төрле формаларда алып барылды: анкеталар үткәрелде, актуаль темаларга консультацияләр бирелде, стендлардагы мәгълүматлар тулыландырылды, ачык ишекләр көне, бердәм бәйрәмнәр күңел ачулар үткәрелде. Әти-әниләр белән бергә 3 гомуми җыелыш үткәрелде. Ел ахырында әти-әниләр өчен төркемнәрдә балалар белән белем эшчәнлеген күрсәтеп җыелыш үткәрелде. База балалар бакчалары белән семинар-практикумнар үткәрелде. Балалар бакчасы мәктәп, авылыбыз китапханәсе белән тыгыз элемтәдә эшли. Ел дәвамында “ бала җанлы шагыйрь абый”темасына язучы Абдулла Алишның “Сертотмас үрдәк әкияте буенча сәхнәләштерелгән күренеш; “ кирәкле кеше урманда файдалы үлән табар”темасына дару үләннәренә багышланга кичә; Россия Геройлары көненә карата “Батырларның юлы бүленмәс!” дип аталган батырлык дәресе уздырылды; Хәкимҗан ага Халиковның әкияте буенча “Бал “бабайда кунакта” дип исемләнгән сәхнәләштерелгән күренеш күрсәттек, Хезмәтбикә, Бал кортлары анасы, Аю кебек әкият персонажлары аша без балаларга хезмәт сөяргә, кеше әйберенә кагылмаска,дөресен сөйләргә кирәклеген аңлаттык ; Уразай авыл китапханәсендә халыкара туган тел көненә карата ”Җырдай моңлы татар теле” дип аталган информация сәгате уздырылды; “Алтын хәзинә” исемле танып- белү сәгате уздырылды.Бу мероприятебезне 1 июнь халыкара балаларны яклау көненә карата уздырдык.Танып- белү сәгатебездә балаларны яңа китаплар һәм балалар китабына багышланган плакат белән таныштырдык. Алар арасында ”Иң күп табышмак белүче” конкурсы уздырдык; “Йөз гөлнең исе бар, йөз таңның төсе бар,гап- гади бер телем икмәктә” дип аталган кичә уздырдык.Без кечкенә балаларга икмәкнең нинди юллар аша табынга килүен,ипинең иң кадерле ризык икәнен, икмәккә карата без нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлекне

шигырьләр, мәкальләр аша аларга җиткердек.Балаларга китапханәче үз китап күргәзмәсен тәкъдим итте.Күмәчкә карата игътибарлы, ихтирамлы булырга өндәде.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, балалар бакчасында тәрбия-йрәтү эше җитәрлек дәрәҗәдә куелган, балаларны өйрәтү, төрле яклап үстерү һәм тәрбияләү эшенә зур игьтибар бирелә, уңай шартлар тудырылган.

Киләчәктә түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк:
тәрбиячеләргә эш тәҗрибәсен уртаклашу уңаеннан төрле күләмнәрдә үткәрелгән конкурсларда һәм семинарларда актив катнашырга

Ел ахырында һәр төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр тарафыннан тәрбия һәм белем бирү программасының үтәлешен билгеләү максатыннан мониторинг үткәрелде. Мониторинг нәтиҗәләре “Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования “От рождения до школы” Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А.Васильева тарафыннан редакцияләнгән программага һәм ФДББС на нигезләнеп ясалды.

Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү эше түбәндәге программалар һәм методик кулланмаларны кулланып башкарылды:

Р.К.Шаехова «Региональная программа дошкольного образования» , Казань, 2012;
Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы», Москва.Мозаика- Синтез, 2014.
**Парциаль программалар:**
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлекКазан “Фолиант”, 2012;
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева “Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык” методическое пособие для воспитателей детских садов 4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет;
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык”: программа, методические рекомендации, диагностика, Казань, 2013;
Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә балалар әлифбасы: “Авазларны уйнатып” , Казан,2011;
К.В.Закирова “Балачак аланы”, балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия, Казан, 2011;

К.В.Закирова “На поляне детства”, хрестоматия для воспитателей детских садов, Казан, 2011;
К.В.Закирова “Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак”, Казан,2012;
К.В.Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, Казан,2005;
К.В.Закирова, Л.Р.Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”, балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма, Казан, 2013;
К.В.Закирова, Р.Ә. Кадыйрова “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” Казан,2013;
З.М.Зарипова “Үстерешле уеннар”, Казан, 2013;
З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова “Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге”, Казан, 2013;
М.Ф.Кашапова «Балалар бакчасында сөйләм үстерү программасы», Казан, 2004;
М.Ф.Кашапова “Иң татлы тел- туган тел”, Казан,2004;
В.Г.Гомәрова, Ф.Я.Зарипова “Бәйрәмнәр бәйләме”, Казан,2005;
Программа по обучению детей русскому языку г.Набережные Челны,2004
К.В.Закирова «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы” , Казан,2005;
Р.К.Шаехова “Иҗади уеннан – укуга”;
Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы “Авазларны уйнатып”. 1-2 кисәкләр, Казан,2011;
Р.А.Борһанова “Туган як табигате белән таныштыру”;
Л.З.Галиуллина, Д.Г.Мансурова “Программа по обучению детей русскому языку”, Набережные Челны, 2004
Л.И. Пензулаева “Физическая культура в детском саду”,младшая группа,Москва,2014;
Л.И. Пензулаева “Физическая культура в детском саду”,средняя группа,Москва,2014;
Л.И. Пензулаева “Физическая культура в детском саду”,старшая группа, Москва,2014;
Л.И. Пензулаева “Физическая культура в детском саду”,подготовительная к школе группа, Москва,2014;
Т.С. Комарова “Изобразительная деятельность в детском саду”, младшая группа,Москва, 2014;
Т.С. Комарова “Изобразительная деятельность в детском саду”, средняя группа,Москва, 2014;
Т.С. Комарова “Изобразительная деятельность в детском саду”, старшая группа, Москва, 2014;
Т.С. Комарова “Изобразительная деятельность в детском саду”, подготовительная к школе группа,Москва, 2014;
Г.А.Галеева, С.М. Гаффарова “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү дәресләре циклы”, Казан,2010;
Д.Г.Әхмәтшина,З.Ф. Камалова “Адымнар нык, юллар имин булсын”, Казан, 2002.

## 2018-2019 нчы уку елына гомуми мәгълүмат.

**Балалар бакчасының методик темасы:**

**“СОЦИАЛЬ МӨХИТКӘ ЯРАКЛАШКАН, СӘЛАМӘТ, КУЛЬТУРАЛЫ, ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛГӘН БЕЛЕМ – КҮНЕКМӘЛӘР ҮЗЛӘШТЕРГӘН, ФДББС НЫ КАБУЛ ИТӘ АЛЫРЛЫК ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮ”.**

**МАКСАТ:** Мәктәпкәчә яшьтәге балалар яшәеше өчен ФДББС таләпләренә туры китереп уңайлы шартлар тудыру**,** ТР ның ике телен дә өйрәтү, шәхес культурасы нигезләре өчен җирлек тудыру, яше һәм шәхси үзенчәлекләре нигезендә баланың төрле яклап үсешенә ярдәм итү, заманча җәмгыятьтә яшәүгә һәм мәктәптә укуга әзерләү, баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

**БУРЫЧЛАР:**

- төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү; тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;

- белем бирү материалын кулланунының вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү; балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

2нче бүлек

# Белем турында законның үтәлеше

| № | Мероприятиеләр | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасының укыту- тәрбия планын төзү. | Август | Мөдир |
| 2 | Белем һәм тәрбия бирүдә тиешле шартлар булдыру | Август | Мөдир |
| 3 | Тәрбияченең һәр белем бирү өлкәсендә яшь үзенчәлекләренә туры китереп эш перспектив планнар төзү. | Август | тәрбиячеләр |
| 4 | Балаларның күңел ачу кичәләрен оештыру. | План буенча | тәрбиячеләр |
| 5 | Балаларның туклануын югары дәрәҗәдә оештыру. | Даими | Мөдир |
| 6 | Балалар бакчасының көндәлек режимын һәм төркемчәләргә бүлеп дәресләр челтәрен төзү, раслау. | Сентябрь | Мөдир, тәрбиячеләр |
| 7 | Балалар бакчасы һәм әти-әниләр арасында килешүләр төзү. | Сентябрь | Мөдир |
| 8 | Сәламәтләндерү эше планы төзү. | Сентябрь | тәрбиячеләр |
| 9 | Балаларның иминлеген һәм хезмәтне саклау инструкциясен үткәрү. | Кварталга бер | Мөдир |
| 10 | Льготага ия булган гаиләләрнең исемлеген булдыру. | Сентябрь | Мөдир |
| 11 | Бакчаның материаль- техник базасын ныгыту. | Даими | Мөдир |
| 12 | ЧС һәм терроризмга каршы комиссияләр төзү. | Сентябрь | Мөдир |
| 13 | Бакчага килүче балаларның төгәл исемлеген булдыру. | Сентябрь | тәрбиячеләр |
| 14 | Бакчада эшчеләрне,аларның балаларын сәламәтләндерү буенча эш. | Даими | Мөдир |
| 15 | Балалар бакчасы, шифаханә һәм СЭС белән килешеп, балаларның исәнлеген, сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру. | Даими | Мөдир |
| 16 | Эвакуация планын барлык эшчеләргә дә җиткерү, бүлмәләр буенча җаваплы кешеләр билгеләү. | Сентябрь | Мөдир |
| 17 | Инвентаризация үткәрү. | Октябрь | Мөдир |

# <u>3 нче бүлек</u>
# Кадрлар белән эшне оештыру

## 3.1. Педагогларны аттестацияләү

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Педагогларның гаризаларын һәм аттестацион материалларын карап үтү | Сентябрь-октябрь | Бадретдинова Р.Я. |
| 2 | Педагогларның иҗади лабораторияләрен, эш документацияләрен тикшерү, әзерләү | Октябрь | Бадретдинова Р.Я. |
| 3 | Аттестация материалларын туплап бетерү | Ноябрь | Бадретдинова Р.Я. |

| №п/п | Педагогның исем, фамилиясе, отчествосы | Вазыйфасы | Нинди категориягә уза |
|---|---|---|---|
| 1. | Марданшина Гульнара Зөфәр кызы | тәрбияче | I-квалификацион категорияне раслау |
| 2. | Садыкова Зөлфия Рафаэль кызы | тәрбияче | I-квалификацион категорияне раслау |

## 3.2. Тәрбиячеләрнең үз белемнәрен күтәрү темасы

| Алынган тема | Ф.И.О |
|---|---|
| ФДББСны тормышка ашыру шартларында ата-аналар белән эш. | Марданшина Г.З |
| Речевое развитие детей в условиях ФГОС | Садыкова З.Р. |

## 3.3.Педагогның социаль активлыгын һәм һөнәри квалификациясен күтәрү

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рус һәм туган теленә өйрәтү буенча дәүләт документлары белән танышуны һәм өйрәнүне дәвам итү. | План буенча | Тәрбиячеләр |
| 2. | “ФДББС кысаларында балаларга белем һәм тәрбия бирүдә информацион комуникатив технологияләрне куллану” темасы буенча материалларны өйрәнү | ел дәвамында | Мөдир, тәрбиячеләр |
| 3. | Үзбелемеңне күтәрү планнары төзү һәм өзлексез эш алып бару, ел азагында нәтиҗә ясау. | ел дәвамында | Мөдир |
| 4. | 2018-2019 нче уку елына балаларга белем һәм тәрбия бирү өлкәләре буенча перспектив планнар төзү | август | Тәрбиячеләр |
| 5.<br>6. | 1.Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшь, 3-4 яшь, 5-6 яшь.,<br>З.М.Зарипова, Л.Н. Вәҗиеваның “Туган телдә сөйләшәбез” , 5-7 яшь,<br>3. Р.К.Шаехова “Авазларны уйнатып” методик кулланмаларын өйрәнүне дәвам итү, тәҗрибә уртаклашу. | даими<br>даими | тәрбиячеләр<br>тәрбиячеләр |
| 7. | “Балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлегендәукыту-методик комплектларның мультимедиа ресурсларыннан файдалану” темасына консультация үткәрү. | декабрь | Садыкова З.Р. |
| 8. | “Федераль дәүләт таләпләренә туры китереп бакчада балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлеген оештыру” темасына семинар-практикум үткәрү. | март | Марданшина Г.З. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | “Ел тәрбиячесе – 2018” республика күләм бәйгесенең муниципаль турында катнашу. | март | тәрбиячеләр |
| 10. | Балаларга укыту – тәрбия бирүдә ФДББС буенча яңа методик әдәбият, әсбапларне көндәлек эшчәнлектә куллану. | даими | тәрбиячеләр |
| 11. | Балалар бакчасының сайтында информацияләрне урнаштырып бару. | даими | Мөдир |

## 3.4.Алдынгы тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Тема: “Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү учреждениясендә ФДББС таләпләрен исәпкә алып,мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү” темасына эш тәҗрибәсе. | март | Садыкова З.Р. |
| 7. | Тема: “Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү учреждениясендә ФДББС таләпләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эти әниләре белән эш алымнары” темасына эш тәҗрибәсе.” | февраль | Марданшина Г.З |
| 9. | Район тәрбиячеләренең фәнни-практик конференциясендә катнашу. | план буенча | тәрбиячеләр |
| 10. | “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү” темасына эш тәҗрибәсеннән методик эшкәртмәләр чыгару өчен материаллар туплау. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |

# IV НЧЕ БҮЛЕК
## Фәнни – педагогик мәгълүмат.
## Методик бүлмәне баету өстендә эш.

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемдэ диагностикалар уздыру. | октябрь-апрель | тәрбиячеләр |
| 2. | Һәр төркем өчен перспектив планнар төзү, яңарту. | август | тәрбиячеләр |
| 3. | Тәрбиячегә үзенең эш юнәлеше буенча методик кулланма чыгару өчен материал туплау. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 4. | Ачык чараларның - белем бирү эшчәнлеге,мастер-класслар, бәйрәм иртәләренең эшкәртмәләрен туплау. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 5. | Уыту-тәрбия процессын Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшь, 3-4 яшь, 4-5 яшь, З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиеваның “Туган телдә сөйләшәбез” , 5-6 яшь, С.М.Гаффарова, Ч.Р.Гаффарованың “Изучаем русский язык”, Р.К.Шаехова “Авазларны уйнатып” методик кулланмаларына нигезләнеп алып бару, тәҗрибә уртаклашу. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 6. | Методик бүлмәдә балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсеннән чыгып төзелгән эшкәртмәләрен туплау**.** | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 7. | Методик почмакны яңаФДББС буенча методик әдәбият белән тулыландырып тору. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 8. | Ике дәүләт телендәге балалар әдәбияты китапларын туплау. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 9 | Тәрбиячегә портфолиосын эш күрсәткечләре буенча тулыландырып тору. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 10 | Ике дәүләт телен өйрәтүдә куллану өчен курчак, бармак театрларын яңарту. | ел дәвамында | тәрбиячеләр |

# Гомуми хезмәт
# коллективы җыелышлары

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | **Яңа уку елына бурычлар**<br>♦ Җәйге сәламәтләндерү чоры нәтиҗәләре.<br>♦ Яңа уку елына әзерлек акты белән танышу<br>♦ Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре б-н танышу Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу.<br>♦ “Эчке тэртип кагыйдэлэре” белән танышу.<br>♦ Аттестациягә әзерлек.<br>♦ Тарификация белән танышу.<br>♦ Балалар бакчасын ягу сезонына әзерләү. | сентябрь | Мөдир |
| 2 | **Уку елының 1 яртыеллыгына анализ.**<br>♦ Укыту-тәрбия эшләренә анализ.Яңа елга әзерлек.Җаваплы кешеләр билгеләү.<br>♦ Бәйрәм көннәренә дежурлык графигы белән таныштыру.<br>♦ Административ- хуҗалык эшләренә анализ.<br>♦ Балаларны сәламәтләндерү нәтиҗәләренә анализ.<br>♦ Балаларны тукландыру сыйфатына анализ.<br>♦ Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре б-н танышу Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу.<br>♦ Отпусклар графигы төзү. | декабрь | Мөдир |
| 3 | **Уку елының үтәлеше нәтиҗәләре.**<br>♦ Укыту-тәрбия эшләренә анализ.<br>♦ Административ- хуҗалык эшләренә анализ.<br>♦ Балаларны сәламәтләндерү нәтиҗәләренә анализ.<br>♦ Балаларны тукландыру сыйфатына анализ.<br>♦ Җәйге сәламәтләндерү чорына әзерлек,җәйге план проекты белән таныштыру.<br>♦ Яңа уку елына бурычлар. | май | Мөдир |

# Педагогик киңәшмәләр

**Педагогик киңәшмә № 1 (установочный)**

**Тема: <u>2018-2019 нче уку елына төп бурычлар.</u>**

***Максат: балаларга тәрбия-белем бирү эше, чыныктыру, сәламәтләндерү эшләре буенча еллык планнар кабул итү, балаларны мәктәпкә әзерләү***

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2017 – 2018 нче уку елына, җәйге сәламәтләндерү эшенә йомгак. | август 2017 | Мөдир |
| 2 | Яңа 2018-2019 нче уку елында алда торган бурычлар, белем һәм тәрбия бирү, укыту-методик комплектларны тормышка ашыру, кулланып эшләү буенча еллык эш планнарын кабул итү. | | Мөдир |
| 3 | 2018-2019 нче уку елына тәрбияченең перспектив планнарын, бердәм аралашу эшчәнлегенең челтәрен, педколлективның эш сәгатьләренең графигын, эшчеләрнең яңа инструктажларын раслау, локаль актлар кабул итү. | | Мөдир |
| 4 | 2018-2019 нче уку елына балаларны сәламәтләндерү буенча эш планы кабул итү. Көндәлек режимны раслау. | | Марданшина Г.З |
| 5 | 2018-2019 нче уку елында балалар бакчасының тормыш иминлеге нигезләрен өйрәнү буенча еллык эш планары белән танышу. | | Садыкова З.Р. |
| ***Педагогик киңәшмәгә әзерлек эшләре*** | | | |
| 1. | Балаларның җәйгеяллары турында . | август | тәрбиячеләр |
| 2 | Планнарны , документларны әзерләү. | август | Мөдир, тәрбиячеләр |

**Педагогик киңәшмә № 2 (тематик)**

**Тема: <u>Балаларның сөйләмен үстерү буенча эшчәнлекне ФДББС таләпләренә туры китереп тагы да камилләштерү, укыту-методик комплектларга нигезләнеп эшләүне дәвам итү</u>**

| | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2018 елда аттестация, яңалыклар үзгәрешләр | ноябрь | Мөдир |
| 2 | “Балалар бакчасында ФДББС таләпләре нигезендә, балаларның экспериментлар аша төрле яклап үстерү юллары. Эш тәҗрибәсе” | | Садыкова З.Р. |
| 3 | Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр тарафыннан тәрбия һәм белем бирү программасының үтәлешен билгеләү максатыннан мониторинг үткәрү. Индивидуаль эш планын өйрәнү, раслау | | Марданшина Г.З. |
| 4 | Ата –аналар белә эш алымнары. Яна ел сценарийын өйрәнү, раслау | | Садыкова З.Р Марданшина Г.З. |
| | ***Педагогик киңәшмәгә әзерлек эшләре*** | | |
| 1. | Аттестация документларын туплау | ноябрь | Мөдир |
| 2 | Укыту методик комплектларны кулланып эшләүдә:экспериментлар уздыру материаллар , методик эшкәртмәләр әзерләүне күзәтү. | Ай дәва-мында | Садыкова З.Р |
| | Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр тарафыннан тәрбия һәм белем бирү программасының үтәлешен билгеләү максатыннан мониторинг үткәрү. Балалар бакчасында ФДББС таләпләре нигезендә, төркемдә ата –аналар белән эш. | | |

**Педагогик киңәшмә № 3**

**Тема: <u>“Нәфис нәфәсәти үсеш” . Тәрбиячеләрнең , балаларның һәм ата-аналарның бердәм коллективын булдыру</u>**

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Алдагы узган педагогик киңәшмәнең карар үтәлеше . Аттестаөия нәтиҗәләре. 2018 нче елга анализ.<br>Балалар бакчасы мөдиренең отчеты белән танышу. | февраль | Мөдир |
| 2 | Нәфис нәфәсәти тәрбия бирүдә халык педагогикасын куллану үзенчәлекләре. | | Садыкова З.Р |
| 3 | Балалар бакчасы һәм гаилә белән эшне оештыру.Чыгыш: “Гаилә һәм балалар бакчасы . | | Марданшина Г.З |
| 5 | Смотр-конкурс Татар халык әкиятләре буенча (балалар, ата-аналар белән берлектә ясаган)<br>рәсем һәм кул эшләре конкурсын оештыру) | | тәрбиячеләр |
| | ***Педагогик киңәшмәгә әзерлек эшләре*** | | |
| 1. | Аттестация нәтиҗәләре. 2018 нче елга анализ. Отчет әзерләү. | январь | Мөдир |
| 2 | Нәфис нәфәсәти тәрбия бирүдә халык педагогикасын куллану үзенчәлекләре. | Ай дәва-мында | .<br>Садыкова З.Р. |
| 3 | Балалар бакчасы һәм гаилә белән эшне оештыру.Чыгыш: “Гаилә һәм балалар бакчасы . Ачык ишекләр көне үткәрү | Ай дәва-мында | Марданшина Г.З.<br>. |

**Педагогик киңәшмә № 4( Йомгаклау)**

**Тема: <u>2018-2019 нче уку елында педагогларның укыту-тәрбия эшчәнлегенең сыйфаты һәм нәтиҗәсе.</u>**

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2018-2019 нче уку елына анализ.<br>Балалар бакчасы мөдиренең публичный доклады белән танышу. | май | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Тәрбиячеләрнең иҗади отчетлары | | |
| 2 | Төркемнәрдә үткәрелгән диагностик күрсәткечләренең нәтиҗәләре (ел ахры). Сәламәтләндерү, чыныктыру буенча эш нәтиҗәләре. Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы кабул итү. | | Марданшина Г.З. |
| 3 | Киләсе уку елының эш планы проекты белән танышу. | | Садыкова З.Р. |
| 4 | Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планын әзерләү | | Садыкова З.Р |
| 5 | Смотр-конкурс<br>Татар халык әкиятләре буенча (балалар, ата-аналар белән берлектә ясаган) рәсем һәм кул эшләре конкурсына нәтиҗә | | тәрбиячеләр |
| | ***Педагогик киңәшмәгә әзерлек эшләре*** | | |
| 1. | Балалар бакчасында белем бирү эшчәнлегенең һәр өлкәсеннән дә йомгаклау эшчәнлекләрен карау. | 10-16 май | Мөдир |
| 2 | Диагностикалар үткәрү. | Апрель | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 3 | Ачык ишекләр көне үткәрү. | Апрель | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 4 | Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планын әзерләү. | Ел дәва-мында | Марданшина Г.З. |
| 5 | Яңа уку елының эш планы проектын әзерләү. | Ел дәва-мында | Садыкова З.Р. |
| 6 | Татар халык әкиятләре буенча (балалар, ата-аналар белән берлектә ясаган) рәсем һәм кул эшләре конкурсы үткәрү | март | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |

# Ачык чаралар

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Зурлар төркемендә сөйләм үстерү һәм грамотага өйрәтү буенча бердәм аралашу эшчәнлеге карау. | ноябрь | Садыкова З.Р |
| 2 | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалрыының элементар математик күзаллауларын формалаштыру буенча бердәм аралашу эшчәнлеге карау. | март | Марданшина Г.З.. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Курчак театры:<br>“Курочка Ряба” | февраль | Садыкова З.Р. |
| 4 | Балалар катнашында татар телендә театр айлыгы үткәрү:<br>“Төлке, куян һәм әтәч” әкияте | апрель | Марданшина Г.З.. |

## Бәйгеләр

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | Жаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Уку елына әзерлек. | Август | Коллектив |
| 2 | “Боз фигуралары патшалыгы” | декабрь | Коллектив |
| 3 | Татар халык әкиятләре буенча (балалар ата-аналары белән берлектә ясаган) рәсем һәм кул эшләре буенча конкурс | Март | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 4 | “Иң матур сыерчык оясы” | март | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 5 | “Ел тәрбиячесе-2018” конкурсында катнашу. | Февраль-март | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 6 | “Яшел ут” конкусында катнашу. | апрель | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 7 | Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү). | апрель | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |

# V НЧЕ БҮЛЕК
# 5.Укыту – тәрбия эшен яхшыртуга юнәлтелгән эшчәнлек.

## 5.1. Сәламәтләндерү, профилактик эш күргәзмәләр

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1.<br><br>2. | **Мониторинг.**<br>Балаларнын физик яктан усеш күрсәткечен билгеләү.<br><br>Балаларнын сәламәтлекләренең торышын һәм чисталыгын даими тикшереп тору тору<br>Балаларнын физик яктан усеш | Сентябрь<br><br>Даими, ел дәвамында | Мөдир һәм тәрбиячеләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрсәткечен билгеләү<br>Чыныктыру ысулларын куллана башлау<br>Авыз һәм тамак чайкау<br>Йокы алдыннан аякларны юу<br>Фитонцидотерапия(суган, сарымсак)<br>Һава ванналары үткәрү<br>Төймәле келәмнән йөрү<br>Чыныктыру чараларының үтәлешен даими контрольдә тоту<br>Нәниләрнең «сетка стула» алып баруны контрольдә тоту<br>Балалар бакчасынын санитария гигиена кагыйдәләренең утәлешен контрольдә тоту.<br>Сәламәтлек саклау министрлыгы курсәтмәсе буенча бирелгән документларны төгәл алып бару.<br>Кинәт авырганда һәм имгәнгәндә врачка кадәр беренче ярдәм күрсәтүне оештыру.<br>Вакытында дез. раствор ясау.<br>Балалар бакчасында көндәлек режимның үтәлешен котрольдә тоту<br>Йогышлы авырулар белән аралашкан балаларның сәламәтлеген<br>күздә тоту<br>Балаларын иртәнге фильтр аша бакчага кертү<br>Бүлмәләрдә һава режимын, бүлмә жилләтүнең үтәлешен тикшереп тору<br>Гимнастика һәм физкультура белем бирү өлкәсе эшчәнлеге үтәлешен контрольдә тоту.<br>Әзерләнгән ризыкларнын сыйфатын тикшереп торырга, киңәшләр бирергә, ризыкны кубрәк төрләндерергә<br>Балаларны саф һавада йөртүне тикшереп тору.<br>Балаларга табиблар язган | Даими, ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | курсәтмәләрне вакытында үтәү, аларны тикшеренү үтәргә жибәрү<br><br>«Алтын көз» балаларның тематик рәсем күргәзмәсе<br><br>**Хәрәкәт эшчәнлеге**<br><br>Иртәнге гимнастика.<br>Физкультура шөгыле ( саф һавада)(Залда)<br>Хәрәкәтле уеннар<br>Көндезге йокыдан соң гимнастика<br>Спорт күнегүләре,уеннары | Ел дәвамында план буенча | |

# 5.2 Ел буе үткәреләчәк “атналыклар”

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| | “Юл әлифбасы” атналыгы | октябрь | Тәрбиячеләр, |
| | «Рус мәдәнияте» атналыгы | гыйнвар | Тәрбиячеләр, |
| | «Татар мәдәнияте» атналыгы | февраль | Тәрбиячеләр, |
| | «Сәнгать һәм гүзәллек» атналыгы | март | Тәрбиячеләр, |
| | «Әдәплелек» атналыгы | май | Тәрбиячеләр, |

**“Юл әлифбасы” атналыгы – октябрь**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөк һәм җиңел машиналар белән таныштыру | 1-нче көн | тәрбиячеләр |
| 2. | Светофор – безнең дустыбыз | 2-нче көн | тәрбиячеләр |
| 3. | Җәяүлеләр-пассажирлар | 3-нче көн | тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Юл билгеләре | 4-нче көн | тәрбиячеләр |

**«Рус милли мәдәнияте» атналыгы – гыйнвар**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | «День книги» (в группе чтение произведений русских писателей). | 1- нче көн | тәрбиячеләр |
| 2. | «День русских народных игр» (в муз.зале со средними, старшими, подгот. к школе группами). | 2- нче көн | тәрбиячеләр |
| 3. | «День русского фольклора» (чтение и обыгрывание потешек, сказок, отгадывание загадок. Просмотр видеофильма о русских народных праздниках). | 3- нче көн | тәрбиячеләр |
| 4. | «День русской музыки» | 4- нче көн | тәрбиячеләр |
| 5. | «День русской сказки» (конкурс рисунков из сюжетов русских народных сказок). | 5- нче көн | тәрбиячеләр |

**“Татар милли мәдәнияте” атналыгы – февраль**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Татар шагыйрьләре һәм язучылары әсәрләре буенча ясалган рәсем конкурсы. | 1-нче көн | тәрбиячеләр |
| 2. | “Уйныйбыз да, җырлыйбыз да” (татар халык җырлы-биюле уеннарын уйнау) | 2-нче көн | тәрбиячеләр |
| 3. | “Әбием сандыгы” (музыкаль-әдәби кичә) | 3-нче көн | тәрбиячеләр, |
| 4. | “Без әкият яратабыз” татар халык әкиятләрен сәхнәләштерү (кечкенә төркемнәр өчен) | 4-нче көн | тәрбиячеләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | “Бар җырымны сиңа багышладым” (М.Җәлилнең иҗаты белән танышу, китапханә эшчеләре белән очрашу һәм М.Җәлилгә багышланган күргәзмә оештыру) | 5-нче көн | тәрбиячеләр | |

**«Сәнгать һәм гүзәллек атналыгы» -март**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балалар өчен дискотека “Кабызгычлар” ( | 1-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 2. | “Күңелле чуклар” мастер-класс. (Уртанчылар төркеме) | 2-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 3. | “Без – кинематографлар” видео презентация. | 3-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 4. | Авыл китапханәсенә экскурсия оештыру | 4-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 5. | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән «Нәүруз» бәйрәмен үткәрү. | 5-нче көн | тәрбиячеләр | |

**«Әдәплелек» атналыгы - май**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның рәсем конкурсы «Әдәпле бала». | 1-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 2. | Һәр төркемдә әдәплелек турында тематик шөгыльләр үткәрү. | 2-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 3. | Әдәплелек, балаларның үз-үзләрен тотышы турында эти-әниләр өчен консультация әзерләү. | 3-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 4. | “Кирлемән маҗаралары” курчак театрын күрсәтү. | 4-нче көн | тәрбиячеләр | |
| 5. | “Әдәпле бала көне”. | 5-нче көн | тәрбиячеләр | |

# 5.3.Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре

| № | Үткәреләчәк мероприятиеләр | Вакыт | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 1.Белем бәйрәме.<br>2.Спорт бәйрәме. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 2 | 1.“Сөмбелә” бәйрәме. | Октябрь | Тәрбиячеләр |
| 3 | 1.“Табышмак әйтәм- уйлап тап.”<br>2. “Әни кирәк!” әнием бәйрәме. | Ноябрь | Тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | 1. “Хуш киләсең Кыш бабай!” | Декабрь | Тәрбиячеләр |
| 5 | 1. Юл йөрү кагыйдәсен өйрәтү буенча күңел ачу кичәсе. | Январь | Тәрбиячеләр |
| 6 | 1.”Мин һәм минем гаиләм” –гаилэ бэйрэме<br>2. Курчак театры:<br>“Репка”<br>“Курочка Ряба” | Февраль | Тәрбиячеләр |
| 7 | 1.”Әнием, алтыным”. Әниләр бәйрәме. “Язны сәламли кошлар.” ”Нәүрүз” бәйрәме. | Март | Тәрбиячеләр |
| 8 | 1. Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү). | Апрель | Тәрбиячеләр |
| 9 | Җиңү бәйрәме | Май | Тәрбиячеләр |
| 10 | 2. “Хуш сөекле бакчабыз.”<br>1.Күңелле сабантуйлар | Июнь | Тәрбиячеләр |

## 5.4.Күренекле шәхесләр белән очрашулар.

| **№** | **Тема** | **Вакыт** | **Җаваплы кеше** |
|---|---|---|---|
| 1 | “И сабый, таян Аллага!” Тәрбия дәресләре. Авылнын олкэн буын кешесе белән очрашу. | Сентябрь | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| | Балалар балалар шагыйрьләре иҗатлары белән танышу. | Ел дәвамында | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |
| 2 | Чәй өстәле янында тыл ветераннары белән очрашу. | май | Марданшина Г.З.<br>Садыкова З.Р. |

## 5.5.Күргәзмәләр

| **№** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | «Алтын көз» балаларның тематик рәсем күргәзмәсе | Октябрь | Садыкова З.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Әниләр көненә багышланган «Минем яраткан әнием» дигән рәсем күргәзмәсе | Ноябрь | Марданшина Г.З. |
| 3 | “Кышкы матурлык” рәсем күргәзмәсе. | Декабрь | Садыкова З.Р. |
| 4 | “ Оста куллар” кул эшләре күргәзмәсе | март | Марданшина Г.З. |
| 5 | Космонавтлар конена багышланкан темага ясалган рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе | апрель | Садыкова З.Р. |
| 6 | « Матур Җәй, кил безгә!”» - балалар рәсем күргәзмәсе | Май | Марданшина Г.З. |

## 5.6. Консультация, әңгәмәләр.

| № | Тема | Җаваплы кеше | Вакыт |
|---|---|---|---|
| 1 | “Мәктәп һәм балалар бакчасы арасында дәвамчанлык” планы буенча фикер алышу. | Укытучылар, мөдир, Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Август |
| 2 | Күмәк җыелышта бакча хезмәткәрләре алдында терроризм турында аңлатмалар алып бару. | Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Сентябрь |
| 3 | Коррупция нәрсә ул? | мөдир | Сентябрь |
| 4 | Балаларның диагностика нәтиҗәләре буенча әңгәмә. | Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Ноябрь Май |
| 5 | ФДББС кысаларында белем һәм тәрбия бирүне планлаштыру. | Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Октябрь |
| 6 | Танып белү эшчәнлеген үстерүдә-театральләштерелгән үзәк | Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Ноябрь |
| 7 | “Балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлегендәукыту-методик комплектларның мультимедиа ресурсларыннан файдалану” темасына консультация үткәрү. | . Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. | Декабрь |

## 5.7.Эшчеләр белән консультацияләр

| № | Эшнең төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | “Бакчаның хезмәтне саклау буенча эчке тәртип кагыйдәләрен беләсеңме?” | Сен-тябрь | мөдир |
| 2. | “Бакчада электр приборларының кулланышына игътибарлы бул!”. | октябрь | мөдир |
| 3. | Балалар белән сәламәтләндерү чаралары.Традицион булмаган сәламәтләндерү алымнары. | ноябрь | Марданшина Г.З. Садыкова З.Р. |
| 4. | “Яңа ел бәйрәме уздыру буенча техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтә!” | декабрь | мөдир |
| 5. | “Кышкы чорда балаларның тормыш именлеген, сәламәтлекләрен саклау барыбызның төп бурычы”. | январь | мөдир |
| 6. | “СанПиНның кагыйдәләрен искә төшерик”. | Февраль | мөдир |
| | | | |

## 5.8. Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **1.** | Яңа уку елына әзерлекләрен тикшерү | уку елы башында | мөдир |
| а<br>б | Тәрбияченең тематик, календарь планнарын тикшерү. Иртәнге гимнастика, эшчәнлекләрне, режим моментларын карау. | ел дәвамында | мөдир |
| в | Төркемнәрдә чыныктыру чараларын үткәрүне контрольда тоту. | ел дәвамында | мөдир |
| г | Тәрбия һәм белем бирү эшенә контрольлек итү. | ел дәвамында | |
| д | График буенча оператив контроль | ай саен | |
| **2.** | **<u>Тематик тикшерүләр</u>** | | |
| 1) | “Төркемдә укыту тәрбия эшеннең торышы, индивидуаль эш планы белән танышу”. | декабрь | мөдир |
| 2) | “Балалар бакчасында ФДББС | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | таләпләре нигезендә, балаларның сөйләм үсеше( зурлар төркеме) укыту методик комплектларны системалы кулланып: интерральләштерелгән белем бирү эшчәнлегенгең торышы”. | апрель | мөдир |

# VI нче бүлек
# Админстратив- хуҗалык эшләре.

| **№** | **Эшләнәчәк эшләр** | **Вакыт** | **Җаваплы кеше** |
|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасының санитария- гигиена тәлапләренң үтәлешен тикшерү. | Ай саен | Мөдир |
| 2 | Балалар бакчасында инвентаризация үткәрү. | Октябрь | Мөдир, җаваплы кеше |
| 3 | Балалар бакчасы территориясенә яңа чәчәклекләр ясау. | Май- август | Коллектив |
| 4 | Бакчада яшелчәләр, чәчәкләр үстерү. | Май- сентябрь | Коллектив |
| 5 | Мебель һәм инвентарьларга маркировкалар билгеләү. | Ел башы | Кече тэрбияче |
| 6 | Комлыкка чиста ком кертү. | Ел башы | Мөдир |
| 7 | Буяу, агарту эшләре. | Август | Коллектив |

# Мәктәп белән элемтә планы

| № | Э ш н е ң т ө р е | Ва к ы т ы | Җ а в а п л ы к е ш е |
|---|---|---|---|
| 1. | “Белем көне” бәйрәменә мәктәпкә бару. | сентябрь | |
| 2. | Укучыларны концерт номерлары белән кунакка чакыру. | кварталга бер тапкыр | Тәрбияләр |
| 3. | укучыларны чакырып сәхнәләштерелгән әкиятләр күрсәтү. | кварталга бер тапкыр | Тәрбиячеләр |
| 4. | укучыларны шефлыкка чакыру. | кварталга бер тапкыр | мөдир |
| 5. | Башлангыч классы укытучыларына ачык занятиеләр күрсәтү. | апрель | Тәрбиячеләр |
| 6. | Мәктәпкә китүче балаларның ата-аналары, башлангыч классы укытучылары, түгәрәк өстәл янында дискуссия үткәрү. | май | мөдир |
| 7. | Укытучыларга мәктәпкә китүче балалар турында белешмә бирү, диагностик тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру. | май | Тәрбиячеләр |

# Җәйге сәламәтләндерү эше планы

| № | Формасы | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Җәйге чорга инструктаж | Май | Мөдир |
| 2 | Хезмәт коллективының җыелышы, җәйге сәламәтләндерү кампаниясенең бурычлары | Май | Мөдир<br>Тәрбияче |
| 3 | Эшчеләрне беренчел ярдәм күрсәтү методларына өйрәтү (травмалар, агуланулар, зарарлы бөҗәкләр тешләве) | Май | Мөдир |
| 4 | Санитар һәм гигиена таләпләре буенча, кояш һәм һава ванналары кабул итү өчен мәйданчыклар әзерләү | Даими, җәйнең азагына кадәр | Тәрбиячеләр, кече тәрбияче |
| 5 | “Сабантуй – 2019”. Татар халкының милли уеннары. | Июнь | Мөдир, тәрбия-че, кече тәрбияче, ата-аналар |
| 6 | “Табигать - туган йортыбыз” дигән темага ата-аналар белән сөйләшү. | Июнь | Тәрбиячеләр |
| 7 | Чәчәкләр бәйрәме | Июль | . Тәрбиячеләр |
| 8 | Рәсемнәр күргәзмәсе | Июль | Тәрбияче |
| 9 | Җәйге спартакиада | Июль | Тәрбиячеләр |
| 10 | “Йомшак су, йөгерек су, син мине чистаю!” Чишмә буена экскурсия | Июль | Тәрбиячеләр |
| 11 | Өстәмә туклану | Даими | Модир |
| | | | |

**Әти- әниләр комитетының эш планы.**

| № | Формасы | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Тема: **“Мәктәпкәчә мәгариф яңалыклары”**<br>1. Узган 2018 – 2019 уку елында балалар бакчасының эшчәнлегенә, эти-әниләр комитеты эшенә кыскача анализ.<br>2. Әти-әниләр комитетының яңа сайланылган членнары белән танышу. Комитетның рәисен, сәркатибен сайлау. Комитетның яңа 2018-2019 уку елына эш планын раслау<br>4. Предметара үстерелешле тирәлеккә бүгенге көн таләпләре. Балалрга белем һәм тәрбия бирүдә үстерелешле мохит нинди урында тора? | сентябрь | Садыкова З.Р.<br><br>Марданшина Г.З. |
| 2 | Тема: **“Балаларның тормыш иминлеген тәэмин итү – өлкәннәрдән тора”**<br>1.Хезмәтне саклау. Пожар куркынычсызлыгы кагыйдәләренең балалар бакчасында үтәлеше. Яңа ел бәйрәменү үткәрүнең куркынычсызлыгын тәэмин итү.<br>2. СанПиН ның яңа санитар-эпидемиологик таләпләре һәм нормалары (РФ Минюсте 29 май, 2013 ел теркәгән, теркәү № 28564).<br>3. Көндезге туклану ризыгының пробасын алу.<br>4. Балаларга бирелә торган белем күләме.<br>5. Чагыштырулы икеара мониторинг нәтиҗәләре.<br>6. “Ватанны саклаучылар”, “Халыкара хатын – кызлар көне” уңаеннан уздырыла торган бәйрәм иртәләрен планлаштыру, әлеге | январь | Садыкова З.Р.<br><br>Марданшина Г.З. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чараларада әти- әниләрнең ролен билгеләү | | |
| 3 | Тема: **“Балаларга белем, тәрбия бирүдә –кулга-кул тотышып!”**<br>1. Балалар бакчасында әти- әниләр өчен “Ачык ишекләр атналыгын” планлаштыру.<br>2. Чыгарылыш бәйрәменә хәзерлек.<br>4. Бала тәрбияләүдә үрнәк булган гаиләләрнең тәҗрибәләрен өйрәнү, сәламәт рәвештә тормыш итүче гаиләләрне барлау, бакча сайтына алар турында фото-мәгълүмат куярга тәкъдим итү. | март | Садыкова З.Р.<br><br>Марданшина Г.З. |
| 4 | Тема: **“Без уку елын ничек уздырдык”**<br>1. Балаларның программа үзләштерү мониторингы нәтиҗәләре.<br>2. Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасы үзләштерүнең йомгаклау (итоговой) нәтиҗәләре.<br>3. Белем бирү сыйфатына ФДБС нинди таләпләр куя? Узган уку елында 1 класска укырга кергән балаларның уку нәтиҗәләре.<br>4. Җәйге ял итүгә хәзерлек эшләре.Чыныктыру чаралары. Балалар бакчасында чәчәклекләрдә, түтәлләрдә эшләр.Балалар бакчасын яңа уку елына хәзерләү.<br>5.Әти - әниләр комитетының | май | Садыкова З.Р.<br><br>Марданшина Г.З. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшчәнлеген, аның балалар бакчасы тормышында тоткан ролен анализлау.Әти - әниләр комитетының еллык эшенә гомуми әти - әниләр җыелышында отчет бирү, балалар бакчасының эшчәнлегенә әти - әниләр күзлегеннән нәтиҗә | | |